КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 сентябрь г.Казань № 801

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель 346 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру турында» 2020 ел, 29 апрель 346 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның ундүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«теләсә кайсы төрдәге балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыру оешмаларына эшкә алынган хезмәткәрләрнең медицина кенәгәләрендә профилактика прививкаларының илкүләм календаре нигезендә йогышлы авыруларга каршы прививка ясалу торышы турында мәгълүматлар, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләрнең мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне, шулай ук аларны башкарганда мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләре үткәрелә торган эшләрне гамәлгә ашыруга карата медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр исемлеген раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 29 номерлы боерыгында каралган медицина каравы һәм тикшерүләре нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, шул исәптән бактериаль һәм вирус этиологиясенең кискен эчәк инфекцияләрен кузгатучыларны билгеләү максаты белән азык-төлек блокларына эшкә керә торган хезмәткәрләрнең; эшчәнлеге азык-төлек продуктлары һәм эчәргә яраклы су

җитештерү, аларны саклау, ташу, реализацияләүгә бәйле булган хезмәткәрләрнең; сууткәргеч корылмаларны эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы затларның лаборатория тикшерүләре турында мәгълүматлар булуны;»;

2 пунктның егерме өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемен автобуслар белән оешкан рәвештә йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге 1177 номерлы карары белән расланган Балалар төркемен автобуслар белән оешкан рәвештә йөртү кагыйдәләре нигезендә балалар йөртүне оештыруны;»;

3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 213 статьясындагы дүртенче өлешендә каралган хезмәткәрләрнең мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләрен үткәрү тәртибен, зарарлы һәм (яки) куркыныч җитештерү факторлары булган эшләрне, шулай ук аларны башкарганда мәҗбүри алдан һәм әледән-әле медицина тикшерүләре үткәрелә торган эшләрне гамәлгә ашыруга карата медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр исемлеген раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 29 номерлы боерыгы таләпләре нигезендә ял оешмаларына эшкә җибәрелә торган персоналга, Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын һәм аларны савыктыруны оештыруга бүлеп бирелә торган акча исәбеннән түләү алмыйча, сезонлы тикшерүләр үткәрүне»;»;

әлеге карар белән расланган Балалар һәм яшьләр ялын һәм аларны савыктыруны оештыру буенча ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Ирина Владимировна Волынецны (килешү буенча) кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин